Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Масягутовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Ул. Дружбы, д. 12, село Масягутово,
Азнакаевский район, 423321

Татарстан Республикасы

Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авылы
җирлеге башкарма комитеты

Дуслык урамы, 12нче йорт,
Мәсгут авылы, Азнакай
районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-2-16; e-mail: Msg.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«29» гыйнвар 2021 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Күмү һәм күмү эше турында» Федераль закон белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6 424,98 (алты мең дүрт йөз егерме дүрт сум, 98 тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http// pravo. tatarstan. ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatarstan. ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Э.Ә.Габдрахманов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башкарма комитет арарына 1 нче кушымта
«29» гыйнвар 2021 ел № 1

**2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә**
**җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 148,98 |
| 2. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 963,00 |
| 3. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 313,00 |
| 4. | **Барлыгы** | 6 424,98 |

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге
башкарма комитет карарына 2 нче кушымта
«29» гыйнвар 2021 ел № 1

**2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| **№** | **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда** |
|---|---|---|
| 1. | Кәфенләү | 841,42 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 307,00 |
| 3. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 963,56 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 313,00 |
| **5.** | **Барлыгы** | 6 424,98 |